# КАРАР

**28 ноябрь, 2022 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

"I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срoклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 2000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Туембаш авылы Ленин урамы юлларына асфальт һәм вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Туембаш авылы Ленин урамнары буенча юлларга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Ленин урамы буенча автомобиль күперен ремонтлау һәм урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Туембаш авылы Ленин урамына балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Туембаш авылы зиратын карап тоту, һәм киртәләү, зират өчен җиһазлар һәм инвентарьлар сатып алу;
- Туембаш авылы урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Туембаш авылының су башнясын буяу өчен материал сатып алу, буяу һәм ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Туембаш авылына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Туембаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, кардан чистарту, җәйге чорда территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Туембаш мәдәният йортын карап тоту (бильярд өстәле сатып алу)»?

«РИЗА»

«КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 391 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 202 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 202 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 2350 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Туембаш авылы Ленин урамы юлларына асфальт һәм вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Туембаш авылы Ленин урамнары буенча юлларга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Туембаш авыл зиратына алып баручы Туембаш авылы юлына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны тормышка ашыру;

- Ленин урамы буенча автомобиль күперен ремонтлау һәм урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Туембаш авылы Ленин урамына балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү;

- Туембаш авылы зиратын карап тоту, һәм киртәләү, зират өчен җиһазлар һәм инвентарьлар сатып алу;

- Туембаш авылы урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Туембаш авылының су башнясын буяу өчен материал сатып алу, буяу һәм ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Туембаш авылына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Туембаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, кардан чистарту, җәйге чорда территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Туембаш авылына керү һәм чыгу билгесе сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

- Туембаш мәдәният йортын карап тоту (бильярд өстәле, проектор, экран сатып алу)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Гарипов